**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**РУКОВОДИТЕЛЬ**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО**
**КОМИТЕТА**
ЧЕРЕМШАНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
**ҖИТӘКЧЕСЕ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30.06.2022 **Чирмешән авылы** **№188**

**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының «Авыл җирлегендә торак төзү һәм сатып алу өчен социаль түләүләр кулланып торак шартларын яхшыртырга теләк белдергән гражданнар исемлегенә кертү һәм социаль түләүләр бирү турында таныклык бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 4 маендагы 205 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карарына таянып, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының «Авыл җирлегендә торак төзү һәм сатып алу өчен социаль түләүләр кулланып торак шартларын яхшыртырга теләк белдергән гражданнар исемлегенә кертү һәм социаль түләүләр бирү турында таныклык бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 4 маендагы 205 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне

кертергә: 1.5 пунктының б пунктчасының 1 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә «авыл территорияләрендә хезмәт килешүе буенча эшчәнлек яки агросәнәгать комплексы өлкәсендә, яисә социаль өлкәдә, яисә авыл хуҗалыгы хайваннары өчен ветеринария эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларда (аларның оештыру-хокукый рәвешләренә бәйсез рәвештә) индивидуаль эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыручы (төп эш урыны), һәм эреләндерелгән һөнәрләр төркеме, "Ветеринария һәм зоотехния" белгечлеге һәм әзерлек юнәлеше буенча урта һөнәри яисә югары белемгә ия булган яки (әгәр дә граждан 35 яшьтән өлкәнрәк булмаса, 35 яшьне дә кертеп) авыл территорияләрендә урман хуҗалыгы оешмаларында хезмәт килешүе буенча эшчәнлек алып баручы».

2. Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының мәгълүматлаштыру бүлегенә өч эш көне эчендә 1 пунктта расланган муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru), шулай ук муниципаль берәмлекләр порталында, Чирмешән муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырганнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе И.Н.Шәйдуллин